РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТУРАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Центральная, д.11А,
с. Тураево, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423627

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Узәк, 11А йорт,
Турай авылы, Менделеев районы,
Татарстан Республикасы, 423627

Тел. (факс): (85549) 2-73-31
e-mail: Tur.Men@tatar.ru

**КАРАР**

2023 елның 20 мае № 4

Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы эш итү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннарны әлеге карарга 1 кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге башлыгы Яхина Гөлнара Багданур кызын терлекләрне элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleeevsk.tatar.ru "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында “Турай авыл җирлеге” бүлегендә (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл башкарма комитеты
җитәкчесе Г.Б.Яхина

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Советының
2023 елның 20 маендагы 4 номерлы
карарына 1 кушымта

Турай авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Хайваннарны стерилизацияләү, билгеләү, исәпкә алу, карантин салу, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яки кешегә карата сәбәпсез агрессивлык күрсәтмәгән хуҗаларсыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына (тоткан урыннардан ) 500 метрдан да якынрак кайтару тыела торган территорияләр:

- фельдшер-акушерлык пункты,
- МФЦ бинасы,
- балалар һәм спорт мәйданчыклары,
- зират